**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Коморгузинского**
**сельского поселения**
**Атнинского муниципального района**
422758, с.Коморгузя, ул. Татарстана, зд.40Б
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Комыргужа авыл жирлеге**
**башкарма комитеты**
422758, Комыргужа авылы, Татарстан урамы., 40Б нчы йорт
Тел./факс.: (8-84369) 32022

---

**КАРАР №7**

Комыргуҗа авылы "08" июль 2025 ел

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә 2025-2029 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасын кабул итү турында»**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен уңай икътисадый мохит формалаштыру максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы 3 өлеше, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль закон, 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә 2025-2029 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасын эшләргә, Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе белән килештерергә һәм 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Комыргуҗа авыл җирлеге территориясендә 2025-2029 елларда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүне тәэмин итү өчен чаралар планын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 14 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә 2020-2024 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасын кабул итү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Комыргуҗа авыл җирлеге
Советы рәисе Хакимов А.А.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 8 июлендәге 7 номерлы карарына 1 нче кушымта

**2025-2029 елларга Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасы**

**Программаның паспорты**

2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасы

**Программаның исеме:** | «2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасы»

**Программаның заказчысы:** | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты

**Программаны эшләүчеләр:** | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты

**Программаның нигезе:** | 1. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон;

2. 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль закон;

3. 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законы;

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы

**Программаның максатлары:** | - Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече бизнесны үстерү өчен оптималь шартлар тудыру;

- икътисади күтәрелеш һәм халыкны эш белән тәэмин итү проблемаларын кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү хисабына хәл итү

**Программаның бурычлары:** | - Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү инфраструктурасын үстерү;
- Кече һәм урта бизнестан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен арттыру;
- Кече һәм урта эшмәкәрлекнең инвестицион активлыгын арттыру;
- Җир мөнәсәбәтләрен камилләштерү һәм җир базарын үстерү;
- Минималь хезмәт хакы дәрәҗәсен минималь куллану бюджетының кыйммәт бәясеннән түбәнрәк булмавын тәэмин итү;
- Бизнес-Хакимият-Җәмгыять коммуникацияләр системасын үстерү;

- Халыкның эшсез өлешен поселокның халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге балансланган икътисади сәясәтен исәпкә алып, кече бизнес өлкәсенә җәлеп итү өчен өстәмә стимуллар тудыру;
- Кече бизнес өлкәсендә эшләүчеләрне социаль яклау белән тәэмин итү;
- Халыкның яшәү шартларын яхшыртуда кече бизнес ролен арттыру.

**Финанслау күләме һәм чыганаклары** | Финанслауның гомуми күләме 4000 сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2025 ел - 0 сум
2026 ел - 1000 сум
2027 ел - 1000 сум
2028 ел - 1000 сум
2029 ел - 1000 сум

Программаны финанслау Әтнә районы Комыргуҗа авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла:
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүгә юнәлдерелгән бюджеттан тыш чыганаклар акчалары (конкрет суммалар күрсәтелмичә, мөмкин булган акча чыганагы буларак фаразлана)

**Программа бүлекләре:**

1. Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече эшмәкәрлек торышын анализлау.
2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү.
3. Программаның көтелгән социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү.
4. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре.
5. Программаның төп чаралары эшләнгән юнәлешләр.
6. Программаны гамәлгә ашыру механизмы.
7. 2025-2029 елларга Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасының төп чаралары.

**1. Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек торышын анализлау**

Базар хуҗалыгы системасы шартларында кече һәм урта эшмәкәрлекнең аерым ролен түбәндәге факторлар билгели:

- мөстәкыйль рәвештә үз иминлеген һәм тормыш дәрәҗәсен тәэмин итүче һәм гражданлык җәмгыятенең төп тотрыклы сәяси көче булган урта сыйныф өлешен арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек секторында яңа эш урыннары булдыру, эшсезлек дәрәҗәсен һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелекне киметү өчен зур потенциал булу;
- халыкның төп массасының иҗтимагый психологиясен һәм тормыш ориентирларын үзгәртү;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең җитештерү структурасын тиз үзгәртү, оператив рәвештә яңа технологияләр һәм фәнни эшләнмәләр булдыру һәм куллану сәләте.

Шуңа бәйле рәвештә Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече эшмәкәрлекне үстерү программасын эшләү һәм тормышка ашыру зарурлыгы туа.

Әлеге Программа 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2007

елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законнар, 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән.

**2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү**

Хәзерге вакытта Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек шактый ныклы позицияләрне биләсә дә, бер төркем проблемалар һаман хәл ителмәгән килеш кала.

Авылда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген үстерүне тоткарлый торган факторлар булып торалар:

- инвестиция ресурсларына керү мөмкинлегенең авырлыгы, кредит ресурсларының авыр алынуы фонында үз финанс чараларының җитәрлек булмавы;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр турында мәгълүматның җитәрлек булмавы, административ киртәләр һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырганда хакимият органнарының ачык регламентлары булмавы.

Эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары ягыннан карарлар кабул итүне һәм гамәлгә ашыруны таләп итә торган проблемалар:

- кече эшмәкәрлек субъектларының социаль җаваплылыгы югары булмавы.

Авылда кече һәм урта эшмәкәрлекнең алга таба прогрессив үсеше мәгълүмати, белем бирү, консультация бирү, финанс юнәлешләрендә комплекслы һәм адреслы ярдәм күрсәтү, эшлекле элемтәләр һәм кооперация урнаштыру, шулай ук башка аспектларда ярдәм күрсәтү юлы белән үсеше өчен уңай шартлар тудыру буенча максатчан эш алып бару нәтиҗәсендә генә мөмкин. Программа җирле хакимият органнарының, шулай ук дәүләти булмаган оешмаларның куелган максатларга ирешү өчен тырышлыкларын берләштерергә һәм оптимальләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

**3. Программаның көтелгән социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү**

Программа Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең алга таба үсеше өчен уңай шартлар тудыруга юнәлтелгән чаралар комплексын үз эченә ала.

Программаны үтәү түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

- районда икътисади һәм социаль тотрыклылыкның иң мөһим элементларының берсе буларак кече эшмәкәрлекнең барлыкка килүен һәм тотрыклы эшчәнлеген стимуллаштыручы уңай икътисади мохит формалаштыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсеш темпларын арттыру, эшчәнлек өлкәләрен киңәйтү һәм кече предприятиеләрне икътисадый ныгыту;
- авыл җирлеге бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәрнең артуы;
- кече эшмәкәрлектә мәшгуль булган хезмәткәрләрнең хезмәт хакы дәрәҗәсен күтәрү, мәшгульлекнең өстәмә мөмкинлекләре барлыкка килү;
- товар базарын җирле җитештерү конкурентлыкка сәләтле продукциясе һәм хезмәтләре белән тулыландыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгын арттыру.

**4. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре**

Халыкның тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән тотрыклы икътисади үсешне тәэмин итү максатларында, эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре билгеләнгән:

- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү;
- халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү;
- транспорт һәм элемтә өлкәсе;
- төзелеш;
- социаль хезмәтләр өлкәсе.

**5. Программаның төп чаралары эшләнгән юнәлешләр**

1. Кече һәм урта эшмәкәрлекнең нәтиҗәле үсеше өчен хокукый базаны камилләштерү һәм административ киртәләрне киметү.
2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс-кредит һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү.
3. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү.
4. Комыргуҗаавыл җирлегендә эшмәкәрнең уңай имиджын һәм кече һәм урта эшмәкәрлек турында уңай иҗтимагый фикер формалаштыру.
5. Кече һәм урта эшмәкәрлек өчен квалификацияле кадрлар әзерләү.
6. Яшьләрнең һәм эшсезләрнең эшмәкәрлек инициативасын үстерүгә ярдәм итү һәм стимуллаштыру.
7. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арасында, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән хакимият органнары арасында партнерлык мөнәсәбәтләре урнаштыруга ярдәм итү.

**6. Программаны гамәлгә ашыру механизмы**

**Программа белән идарә итү** | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты

**Программаны финанслау** | РФ, ТР бюджеты, җирлек бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, кече бизнес субъектларының үз акчалары

**Программаның төп башкаручылары** | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты

**Программаның үтәлешен контрольдә тоту** | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советы

**7. 2025-2029 елларга Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасының төп чаралары**

| **Бурычның исеме** | **Төп чараларның исеме** |
|---|---|
| Кече һәм урта бизнес субъектлары санын арттыру. Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге кече эшмәкәрлек субъектларының конкурентлыкка сәләтлелеген арттыру | Кече һәм урта эшмәкәрлеккә мәгълүмати ярдәм күрсәтү, Интернет челтәрендә Әтнә муниципаль районының рәсми порталында «Кече һәм урта бизнес субъектлары өчен мәгълүмат» битенең эшләвен тәэмин итү, эшмәкәрлек җәмәгатьчелеге белән коммуникацияләр өчен өстәмә мәйданчыклар булдыру һәм алып бару |
| Кече һәм урта бизнеста мәшгуль | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына әзерлек, |

| **Бурычның исеме** | **Төп чараларның исеме** |
|---|---|
| булганнарның эш сыйфатын һәм хезмәт шартларын яхшырту, кече һәм урта бизнес субъектларының конкурентлыкка сәләтлелеген арттыру | яңадан әзерлек һәм квалификацияне күтәрү өлкәсендә, хезмәт саклау һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренә өйрәтү курслары мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтү. Хезмәт саклау, хезмәт шартларын махсус бәяләү, хезмәт законнары мәсьәләләре буенча методик ярдәм |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының имиджын, эшлеклелек активлыгын арттыру, яшьләрнең үз бизнесын алып баруда компетенцияләрен һәм күнекмәләрен үстерү | "Түгәрәк өстәлләр", конференцияләр, семинарлар, конкурслар һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән башка чаралар үткәрү юлы белән яшьләр арасында эшмәкәрлек эшчәнлеген пропагандалау һәм популярлаштыру. Мәктәпләрдә ачык дәресләр, эшмәкәрләр белән очрашулар, конкурслар үткәрү. |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәменең чараларын гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгы линиясе буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программалары белән таныштыру. Ярдәм чараларын алуда булышлык күрсәтү. |

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Комыргуҗа авыл җирлеге
башкарма комитетының 2025 елның «08»
июля 7 номерлы карарына 2 нче кушымта

**2025-2029 елларда Комыргуҗа авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен чаралар планы**

1. Комыргуҗа авыл җирлеге территориясендә кече эшмәкәрлеккә ярдәм инфраструктурасын үстерү.
2. Мәгълүмат бирү, консультация һәм укыту.
3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын торак булмаган биналар белән тәэмин итү.
4. Җирлек яшьләрен эшмәкәрлек эшчәнлегенә актив җәлеп итү, аларның социаль-хезмәт адаптациясенә ярдәм итү.
5. Шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итү системасын үстерү.
6. Авыл хуҗалыгында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру.
7. Кече һәм урта бизнеска салым һәм административ йөкләнешне оптимальләштерү, эшмәкәрлек эшчәнлеге милек хокукларын яклау.
8. Эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары эшчәнлеген контрольдә тоту һәм күзәтү буенча чаралар системасын камилләштерү